ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РУССКО-ОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422642, Рус Әшнәге авылы,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт,

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail: Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.06.2019 Рус Әшнәге авылы №6

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының норматив чыгымнарын, норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен, тәүлеклек юл узу (пробег) нормативларын, агымдагы карап тотуга киткән чыгымнарны компенсацияләү күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларыннан файдалануның, шулай ук аларны тоту чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 1 декабрендәге "Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына һәм алар карамагындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының норматив саны, юл узуы һәм агымдагы тотуга чыгымнар турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының көчен югалтуын тану хакында"гы 1073 номерлы карары, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аның карамагындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларының норматив саны, юл узуы һәм агымдагы тотуга чыгымнар турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының көчен югалтуын тану хакында" 2018 елның 1 декабрендәге 1073 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 7 мартындагы 165 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга (кушымта итеп теркәләләр):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чаралары өчен юл узу (пробег) нормативларын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге

авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен;

Шәхси транспортны хезмәт урыны максатларында файдаланган өчен компенсация турында Нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын машина йөртүчеләреннән башка файдаланганда агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны.

2. Әлеге карарның рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керүен билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы В.Х.Хажиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Рус Әшнәге авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның  14 июнендәге
6 номерлы карарына
кушымта  №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче  транспорт чаралары өчен юл узу (пробег) нормативлары

| № п/п | Хезмәт урынында транспорт чарасы беркетелү  каралган вазифа  атамасы | Командировкаларга барып кайтуны (зарур булганда) исәпкә алып транспорт чараларының  юл узу нормативы, км елга | Командировкаларга барып кайтуны (зарур булганда) исәпкә алып транспорт чараларының  юл узу нормативы, км тәүлеккә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы | 17 010 | 70 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл
җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 14 июнендәге
6 номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт
чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны
исәпләү Тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне, микроавтобус (фургон), автобус, йөк автомобильләрен агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне, микроавтобус (фургон), автобус, йөк автомобильләрен машина йөртүчеләреннән башка файдаланганда аларны агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнарны исәпләү тәртибен билгели.

2. Җиңел автомобильләрне, микроавтобус (фургон), автобус, йөк автомобильләрен тотуга чыгымнар тотуга сарыф итүләрнең база өлешенә һәм транспорт чараларын 1 км юл узу өчен эксплуатацияләүгә киткән сарыф итүләргә бүленә.

Транспорт чарасын тотуга сарыф итүләрнең база өлеше транспорт чарасын бер ел эксплуатацияләүгә исәпләнә һәм түбәндәге чыгымнарны үз эченә ала:

машина йөртүченең хезмәтенә түләүне һәм хезмәт хакын исәпләүне тиңдәшле рәвештә($З_1$, $З_2$);

транспорт салымын($З_3$);

автогражданлык җаваплылыгын иминиятләүне ($З_4$);

автомобильгә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтны ($З_5$);

автомобильгә техник карау уздыруны ($З_6$);

командировкада машина йөртүченең туклануына һәм торуына сарыф итүләрне ($З_7$).

Транспорт чараларын 1 км юл узу өчен эксплуатацияләүгә киткән сарыф итүләр түбәндәге чыгымнарны үз эченә ала:

автомобиль шиннары булдыруны ($З_8$);

ягулык-майлау материалларын ($З_9$);

башка чыгымнарны ($З_{10}$).

2.1. Машина йөртүченең хезмәтенә түләү ($З_1$) Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә исәпләнә. Машина йөртүченең хезмәтенә түләү 2000 елның 19 июнендәге "Минималь хезмәт хакы күләме турында" 82-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларына каршы килә алмый.

2.2. Хезмәткә түләүгә исәпләүләр ($З_2$) Россия Федерациясе законнары нигезендә исәпләнә.

2.3. Транспорт салымы ($З_3$) Татарстан Республикасының 2002 елның 29 ноябрендәге "Транспорт салымы турында"гы 24-ЗРТ номерлы Законы нигезендә исәпләнә.

2.4. Автогражданлык җаваплылыгын иминиятләүгә чыгымнар ($З_4$) һәрбер транспорт чарасы өчен асылдагы мәгълүматлары буенча алына. Кулланылышка яңа кертелгән автомобильләргә елга 13 680 сумга тигез зурлык алына.

2.5. Автомобильгә бер мәртәбә техник хезмәт күрсәтүгә ($З_5$) норматив чыгымнар зурлыгы бәясе 1,2 млн. сумнан артмаган автомобильләр өчен елга 9 600 сум итеп һәм бәясе 1.2 млн. сумга тигез яисә аннан артык булган автомобильләр өчен елга 25 920 сум итеп алына.

Автомобильгә техник хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар зурлыгы ($З_5$) түбәндәге формула буенча исәпләнә: $З_5 = Ст_{ТО} \times \left(\frac{Пр_{норм}}{15\,000}\right)$,

биредә:

$Ст_{ТО}$ – автомобильгә бер тапкыр техник хезмәт күрсәтү бәясе, сумнарда;

$Пр_{норм}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив еллык узган юл.

2.6. Автомобильгә техник карау уздыруга ($З_6$) чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 27 декабрендәге "Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник карау уздыру өчен түләүнең чик күләмнәрен билгеләү турында" 1079 номерлы карары нигезендә алына.

2.7.Командировкада машина йөртүченең торуына һәм тукланыуына сарыф итүләр ($З_7$) елга 14 976 сум итеп алына (әлеге максатларда Татарстан Республикасының бюджет оешмалары тарафыннан тотыла торган уртача статистик зурлык буларак).

2.8. Автомобиль шиннары булдыруга ($З_8$) (1 км юл узуга) сарыф итүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_8 = Ст_ш \times К_ш / 60\,000\ ,$$

биредә:

$Ст_ш$ – бер автомобиль шинының уртача бәясе (җәйге һәм кышкы шиннарны алыштыруның зарурлыгын исәпләп), сумнарда;

$К_ш$ – бер автомобиль өчен кирәк булган шиннар саны;

60 000 – шин өчен юл узу нормативы, км.

2.9. Ягулык-майлау материалларына ($З_9$ ) (1 км юл узуга) сарыф итүләр

түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_9 = Q_{норм}/100 \times Ст_{топл} \times К_{масл} ,$$

биредә:

$Q_{норм}$ – транспорт чарасы өчен ягулыкның норматив чыгымы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Q_{норм} = Q_{баз} \times (1 + 0{,}01 \times D),$$

биредә:

$Q_{баз}$ – ягулык чыгымының төп (нигез) нормасы, л/100 км;

D – нормага төзәтмә коэффициент (кушудан килеп чыккан гомуми чагыштырма өстәмә (өстәү) яки киметү);

$Ст_{топл}$ – алдагы чорның ахырына автомобиль ягулыгының уртача статистик бәясе,Татарстанстат мәгълүматларына ярашлы рәвештә алына, сум;

$К_{масл}$ – автомобиль майларына һәм майлау-сылау материалларына чыгым коэффициенты, 1,08 гә тигез итеп алына.

$Q_{баз}$ һәм D зурлыклары Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның 14 мартындагы ""Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материалларының чыгым нормалары" Методик рекомендацияләрен гамәлгә кертү турында" АМ-23-р номерлы күрсәтмәсендә (боерыгында) күрсәтелгән нормаларга туры китереп алына.

2.10. 1 км юл узуга башка чыгымнар ($З_{10}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_{10} = (З_8 + З_9) \times 0{,}07.$$

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне, микроавтобус (фургон), автобус, йөк автомобильләрен агымдагы тотуга норматив еллык сарыф итүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$НФЗ_{В1} = \sum_{i=1}^{7} З_i + \sum_{i=8}^{10} (З_i) \times Пр_{норм} ,$$

Биредә: $Пр_{норм}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив еллык узган юл (пробег).

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне, микроавтобус (фургон), автобус, йөк автомобильләрен машина йөртүчеләреннән башка файдаланганда аларны агымдагы тотуга норматив еллык сарыф итүләр ($НФЗ_{В2}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$НФЗ_{В2} = \sum_{i=3}^{7} З_i + \sum_{i=8}^{10} (З_i) \times Пр_{норм}.$$

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 14 июнендәге
6 номерлы карарына
кушымта №3

Шәхси транспортны хезмәт урыны максатларында
файдаланган өчен компенсация турында
Нигезләмә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына яисә урындагы затына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән җиңел автомобиль беркетелү каралып, Башкарма комитет яки урындагы зат хезмәт урыны максатларында шәхси җиңел автомобилен файдалана яки читтәге оешмаларның транспорт хезмәтләреннән файдалау очрагында Башкарма комитет яисә мондый вазифаи зат өчен транспорт хезмәтләренә сарыф итүләргә компенсация алу каралган, ул бер җиңел автомобильгә көнгә 460 сум яки айга 9 320 сум күләмендә.

Транспорт хезмәтләренә сарыф итүләрне компенсацияләү (каплау) фәкать җиңел автомобильләр өчен генә каралган һәм бары тик җиңел автомобильләрнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән норматив саны кысаларында гына рөхсәт ителә. Башкарма комитетка яки вазифаи затка норматив хокукый акт белән җиңел автомобильләр беркетү каралмаган булса, транспорт хезмәтләренә сарыф итүләргә компенсация алу рөхсәт ителми. Транспорт хезмәтләренә сарыф итүләрне компенсацияләү файдаланыла торган җиңел автомобильләрнең маркасына бәйсез рәвештә бердәм (гомуми) булып тора һәм учреждение яки вазифаи зат тарафыннан шәхси җиңел автомобильне хезмәт максатларында файдалануның яисә чит оешмаларның транспорт хезмәтләреннән файдалануның бөтен тулы көннәрен исәпкә алып түләнә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2019 елның 14 июнендәге
6 номерлы карарына
кушымта №4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче
транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнар

| Транспорт чарасының маркасы | Транспорт чараларын тотуга сарыф итүләрнең база (нигез) өлеше, елга сумнарда | 1 км юл узуга сарыф итүләр, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җиңел автомобиль | | |
| ChevroletNiva 212300-55 (ВАЗ-21213) | 237 220 | 6,79 |
| FiatAlbea 1.4 | 237 190 | 4,77 |
| LADA 4X4 (ВАЗ 2121, 2131) | 237 250 | 6,21 |
| FiatDoblo 1.4 | 237 190 | 5,35 |

Искәрмәләр.

Таблицада булмаган транспорт чаралары маркалары өчен транспорт чаралары (таблицада китерелгәннәрдән) двигателенең егәрлеге һәм эшче күләме, шулай ук 100 км ара узуга ягулык чыгымы буенча охшашлык методын файдаланып компенсация күләмнәре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл жирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 14 июнендәге
6 номерлы карарына
кушымта №5

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетына хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын машина йөртүчеләреннән башка файдаланганда агымдагы тотуга норматив еллык чыгымнар

| Транспорт чарасының маркасы | Транспорт чараларын тотуга сарыф итүләрнең база (нигез) өлеше, елга сумнарда | 1 км юл узуга сарыф итүләр, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җиңел автомобиль | | |
| ChevroletNiva 212300-55 (ВАЗ-21213) | 39 480 | 6,79 |
| FiatAlbea 1.4 | 39 450 | 4,77 |
| LADA 4X4 (ВАЗ 2121, 2131) | 39 510 | 6,21 |
| FiatDoblo 1.4 | 39 450 | 5,35 |

Искәрмәләр.

1. Машина йөртүчесеннән башка файдалануга фәкать җиңел транспорт чаралары гына рөхсәт ителә
2. Таблицада булмаган транспорт чаралары маркалары өчен транспорт чаралары (таблицада китерелгәннәрдән) двигателенең егәрлеге һәм эшче күләме, шулай ук 100 км ара узуга ягулык чыгымы буенча охшашлык методын файдаланып компенсация күләмнәре кулланыла.